КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 7 апрель г.Казань № 683

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

конкурс комиссиясе составыннан К.Н.Пономаревны, И.С.Сәгыйтовны, Р.Р.Гарифуллинаны чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Морозов Кузьма Николаевичны | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының мәдәният һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек комиссиясе әгъзасы, конкурс комиссиясе рәисе урынбасарын (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Бакунина Альбина Гомәр кызын | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү идарәсе башлыгын, конкурс комиссиясе секретарен |
| Әмирова Айгөл Тәлгать кызын | «Татарстан Республикасы эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенең җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр буенча белгече (килешү буенча); |

Э.Ф.Әхмәтова вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе»;

В.З.Гарифуллин вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирә торган федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең татар журналистикасы кафедрасы мөдире, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге Президиумы әгъзасы (килешү буенча)»;

В.З.Латыйпова вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирә торган федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе профессоры, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин